**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**№ 157** **от 07.03.2019 ел**

**Татарстан Республикасының Спас
муниципаль районында 2019-2023 елларда
кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү
программасын раслау турында**

Спас муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә уңай шартлар тудыру максатында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2013 елның 06.10 №131нче Федераль закон, “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында” 2007 елның 24.07.№ 209нчы Федераль законга һәм “Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында”гы 2010 елның 21.01 №7 Законына нигезләнеп, Спас муниципаль районы Башкарма комитеты чыгарган

**К А Р А Р:**

1. Татарстан Республикасының Спас муниципаль районында 2019-2023 елларга кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү Программасын (1нче кушымта) расларга.
2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында(//htth:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.
3. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетының “2018-2022 елларда Татарстан Республикасының Спас муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү программасын раслау турында” гы 2017 елның 26 декабрендәге 911нче карарын гамәлдән чыккан дин санарга.
4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне башкарма комитет җитәкчеснең икътисад буенча урынбасары Р.Р.Закировага йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы башкарма
Комитеты җитәкчесе В.А.Осокин

Татарстан Республикасы
Спас муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 07.03 №157 карары
белән расланган

# Татарстан Республикасының Спас муниципаль районында 2019-2023 елларда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү программасы

Болгар шәһәре
2019ел.

ЭЧТӘЛЕК

I.Программаның паспорты ........................................................................ 3
II. Кыскача кереш ........................................................................ 6
III. Программаның гомуми өлеше ........................................................................ 6
**1**. Программаның максаты һәм бурычлары ........................................................................ 6
**2**. Агымдагы хәлләргә анализ, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү проблемаларына бәя ........................................................................ 7
**3**. Икътисад тармакларында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү ........................ 9
**4**. Кулланучылар базарының үсеше ........................................................................ 10
**5**. Яшьләр арасында эшмәкәрлекнең үсүе ........................................................................ 15
**6**. Промышленность мәйданчыгының үсүе һәм резидентлар җәлеп итү ........... 17
**7**. Халыкның үзмәшгульлеге ........................................................................ 18
IV. Территорияләргә җәлеп ителгән инвестициягә бәя, эшмәкәрлекне үстерүнең юнәлешләре һәм конкрет чаралар исемлеге ........................................................................ 19
V. Программаның ресурслар белән тәэмин ителеше ........................................................................ 23
VI. Очракларга бәя бирү, аларныбетерү буенча чаралар ........................................................................ 25
VII. Программаның планлаштырылган икътисадый нәтиҗәлелеге, Программа белән идарә итү һәм аның үтәлешенә контроль
VIII. Нәтиҗәләр һәм кушымталар ........................................................................ 28
IX. Программаның төп чаралары ........................................................................ 30

# I. Программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында 2019-2023 елларга кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү Программасы (аннары - Программа) |
| Программаның төп эшләүчесе | Спас муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге |
| Программаның бурычлары һәм максаты | Муниципаль Программаның максаты:<br>Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен уңай шартлар белән тәэмин итү, шулай ук аның Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш бурычларын хәл итүдә нәтиҗәлелеген арттыру.<br>Муниципаль Программаның бурычлары:<br>- Спас муниципаль районындагы кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү темпларын арттыру;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлекнең көндәшлек сәләтен һәм инвестицион яктан җәлеп итүчәнлеген арттыру;<br>- яшьләр арасында эшмәкәрлекне үстерүгә булышу;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына кадрлар әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү системасын үстерү;<br>- Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының мәдәни-тарихи мирасын саклау һәм популярлаштыру тармагында эшләүчеләрнең (төрле әйберләр җитештерү, туризм, шәһәр төзелеше h.б.) бизнесен үстерүдә ярдәм итү;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүнең финанс, икътисадый, социаль һәм башка күрсәткечләренә анализ;<br>- эшмәкәрлек эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасын камилләштерү;<br>- урта һәм кече бизнесның социаль җаваплылыгын һәм нәтиҗәлелеген арттыру. |

<table>
<tr><td>Максатчан индикаторлар һәм Программаның күрсәткечләре</td><td>1. Кече һәм микропредприятиеләр саны.<br>2. Кече предприятиеләрдә )шул исәптән микропредприятиеләрдә) эшләүчеләр саны.<br>3. Микропредприятиеләрдә акча әйләнеше ( микропредприятиеләрне дә кертеп).<br>4. Микропредприятиеләрдә эшләүчеләрнең айлык хезмәт хакы (шул исәптән микропредприятиеләрдә).<br>5. Җирле бюджетка кече һәм урта бизнестан кергән салым һәм салым булмаган керемнәр.<br>6. Тулаем территориаль продуктта кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының өлеше.</td></tr>
<tr><td>Программаның этаплары һәм үтәлү вакыты</td><td>2019 - 2023 еллар</td></tr>
<tr><td>Программаны үтәүчеләр</td><td>Спас муниципаль районы Башкарма комитетының вәкаләтле структур подразделениеләре; иҗтимагый оешмалар; кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары.</td></tr>
<tr><td>Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td>Программаны финанслауның гомуми күләме 12440,0 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 4440,0 мең сум, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы акчасы – 8000,0 тыс. рублей.
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы (мең сумнарда)</th><th>ТатарстанРеспубликасы Спас муниципаль районы бюджеты акчасы (мең сумнарда)</th><th>Барлыгы</th></tr>
<tr><td>2019</td><td>888,0</td><td>1600,0</td><td>2488,0</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>888,0</td><td>1600,0</td><td>2488,0</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>888,0</td><td>1600,0</td><td>2488,0</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>888,0</td><td>1600,0</td><td>2488,0</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>888,0</td><td>1600,0</td><td>2488,0</td></tr>
</table>
Искәрмә: финанслау күләмнәре фаразлар нигезендә генә каралган һәм бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып ел саен үзгәртелергә дә мөмкин.</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| Программаның үтәлешенә контроль | Ведомствоара координацияне<br>Һәм программа чараларының үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасының Спас муниципаль районы Башкарма комитеты алып бара,Программаны тормышка ашыру өчен бирелгән акчаның ничек тотылуына үз вәкаләтләре кысаларында “Спас муниципаль районы” муниципаль берәмлекнең финанс-бюджет палатасы, Контроль-хисап палатасы контрольлек итә. |
| Программаны тормышка ашыруның төп нәтиҗәләре | Программаны тулы күләмдә үтәү 2023 ел азагында түбәндәге үсешкә ирешү мөмкинлеге бирәчәк:<br>- тулаем территориаль продуктта кече һәм урта бизнесның өлеше 30% ка җитәчәк;<br>- барлык кече предприятиеләр хезмәткәрләренең уртача исемлеге саны (вазифаларны башка үтәүчеләрдән кала) барлык предприятие һәм оешмалардагы уртача исемлектәге саннан (вазифпларны башка үтәүчеләрдән кала) 23%ка җитәчәк;<br>-кече предприятиеләрдә эшләүчеләрнең айлык уртача хезмәт хакы 19 мең сумга җитәчәк;<br>-кече һәм урта прелприятиеләрдән салым һәм салымныкы булмаган керемнәр күләме җирле бюджетта 71,9 млн. сумга җитәчәк. |

## II. КЫСКАЧА КЕРЕШ

Татарстан Республикасының Спас муниципаль районында кече һәм урта бизнес субъектларын 2019-2023 елларга кадәр үстерү программасы (аннары Программа) “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында”гы 24.07.2007 елгы 209нчы-ФЗ Федераль закон; “Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында”гы 21.01.2010 елгы 7нче-ЗРТ Законына, “Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында”гы 2014 елның 28 июнендәге 172нче Федераль законның төп положениеләренә, “Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында”гы 2015 елның 16 мартындагы 12нче Татарстан Республикасы законына, “Татарстан Республикасының 2030 елга кадәр социаль-икътисадый үсеш Стратегиясен раслау турында”гы 2015 елның 15 мартындагы 40нчы Татарстан Республикасы законы һәм Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына еллык юлламасына нигезләнеп үтәлә.

Татарстан Республикасының Спас муниципаль районында 2019-2023 елларга кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү программасы территорияләрнең икътисадын һәм социаль тармагын 2023 елга кадәр үстерү өчен территорияләрне үстерүнең мөһим юнәлешләрен билгеләү максатында эшләнде.

## III. ПРОГРАММАНЫҢ ГОМУМИ ӨЛЕШЕ

### 1. Программаның максаты һәм бурычлары

Программаны тормышка ашыруның максаты – Татарстан Республикасы Спас муниципаль районындагы кече һәм урта эшмәкәрлек объектларын үстерү өчен уңай шартлар булдыру, шулай ук эшмәкәрлек объектларының Татарстан республикасы Спас муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш бурычларын хәл итүгә кертә торган өлешен яхшыртудан гыйбарәт.

Алда торган максатка ирешү өчен түбәндәге әһәмиятле бурычларны хәл итәргә:

- Спас муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү темпларын яхшыртырга;
- кече һәм урта эшмәкәрлекнең конкурентлык сәләтен арттыру һәм инвестицияләр җәлеп итүне җайга салу;
- яшьләр арасында эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү;
- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына кадрлар әзерләү һәм кадрларның квалификациясен күтәрү системасын үстерү;
- Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының мәдәни-тарихи мирасын саклау һәм популярлаштыру буенча алып барыла торган кече бизнесны (туризм, шәһәр төзелеше, төрле сувенирлар ясау) үстерүгә

булышлык итү),

шулай ук:

- кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүнең финанс, икътисадый, социаль һәм башка күрсәткечләренә анализ;

- эшмәкәрлек эшчәнлеген матбугатта яктырту системасын камилләштерү;

- кече һәм урта бизнесның социаль җаваплылыгын һәм нәтиҗәлелеген яхшырту.

## 2. Агымдагы хәлгә анализ, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү проблемаларына бәя

Хәзерге вакытта эшмәкәрлек, кече һәм урта бизнес шәһәр һәм район тормышында әһәмиятле роль билэп тора. Кече бизнес предприятиеләре район икътисадының төрле тармакларында: промышленность, авыл хуҗалыгы, төзелеш, транспорт, сәүдә тармагында эш алып баралар. Кече һәм урта эшмәкәрлек район икътисадында, салым салына торган базаны булдыруда, халык ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә сизелерлек урын били. Кече һәм урта бизнесның социаль пландагы роле дә бик зур: кече эшмәкәрлек халыкны эш белән тәэмин итү проблемасын хәл итә, базарны төрле товарлар белән тәэмин итә, предприятиеләр төзелеп яңа эш урыннары булдырыла. Атап әйткәндә, кече эшмәкәрлек район икътисадында торган саен зур һәм әһәмиятле роль уйный, җәмгыятьтә социаль һәм икътисадый тотрыклылыкның мөһим бер факторы булып тора. Безнең районда да кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә аерым игътибар бирелүе бер дә гаҗәп түгел.

2018 елның 1 гыйнварына Спас районында 423 кече бизнес субъекты үз эшчәнлеген алып барды, шуның 85е – кече һәм микропредприятиеләр, 338е – шәхси эшмәкәрләр.

Райондагы кече һәм микропредприятиеләрдә 640 кеше эшли. Кече предприятиеләрдә хезмәт куючыларның саны районда барлык эшләүчеләрнең гомуми санынннан 640 кешене тәшкил итә. Кече предприятиеләрдә эшләүчеләр саны райондагы барлык эшчеләр санынннан 21 процент тәшкил итә. Ягъни, районда эшли торган һәр алтынчы кеше үз эшчәнлеген кече предприятиедә алып бара.

2017 елда кече һәм микропредприятиеләрдә эшләүчеләрнең хезмәткә түләү фонды 112138,75 мең сум тәшкил итте. 2017 елда кече һәм микропредприятиеләрдә эшләүчеләрнең уртача хезмәт хакы 14601,4 сумга җитте. ФОТ работников малых и микропредприятий на 2019 елда кече һәм микропредприятиеләрдә эшләүчеләрнең хезмәткә түләү фонды 119970,0 сумга җитәргә тиеш. Аларның уртача айлык хезмәт хакы 15500 сум булыр, дип планлаштырыла.

Кече предприятиеләрнең акча әйләнеше (микропредприятиеләрне дә кертеп) 939,4 миллион сум (2015 елдагыга караганда 17 процентка күп)

тәшкил итте. 2019 елда кече предприятиеләрнең акча әйләнеше (микропредприятиеләрне дә кертеп) 950,0 миллион сум күләмендә фаразлана.

Гомумән алганда, бүген кече һәм урта бизнес тулаем территориаль продуктның чиреген (28,7 процент) тәшкил итә. 2019 елда кече һәм урта бизнес субъектларының тулаем территориаль продукттагы өлеше 29 процентка җитәр, дип планлаштырыла.

Татарстан Республикасының Спас муниципаль районында эшмәкәрлек тармагын үстерүнең төп тенденцияләр

Таблица 1

| Күрсәткечләрнең исемлеге | 2015 год (факт) | 2016 год (факт) | 2017 год (факт) | 2018 год (оценка) |
|---|---|---|---|---|
| Кече һәм микропредприятиеләрнең саны, берәмлекләрдә | 92 | 81 | 85 | 85 |
| Кече предприятие хезмәткәрләренең (микропредприятиеләрне кертеп) саны, кешеләр | 666 | 636 | 640 | 642 |
| Кече предприятиеләрнең (микропредприятиеләрне кертеп) акча әйләнеше, млн. сумнарда | 802,9 | 981,1 | 939,4 | 943,5 |
| Кече предприятиеләрдә (микропредприятиеләрне кертеп) эшләүчеләрнең уртача айлык хезмәт хакы, сумнарда | 14912,3 | 14021,0 | 14601,4 | 14820,0 |
| Салым органнарында теркәлгән (яңадан теркәлгән) эшмәкәрләрнең саны, кешеләр | 335 | 341 | 338 | 340 |
| Шәхси эшмәкәрләрне исәпкә алып, кече предприятиеләрдә эшләүчеләр саны, кешеләр | 1001 | 977 | 978 | 982 |
| Тулаем территориаль продуктта кече һәм урта бизнесның өлеше, процентларда | 27,4 | 28,0 | 28,7 | 29,0 |
| Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары белән төзелгән муниципаль контрактлар, данә | 53 | 103 | 113 | 185 |
| Барлык төзелгән муниципаль контрактларда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының өлеше, процентларда | 74 | 83 | 34 | 49 |

2018 елда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан сораштыру нәтиҗәләренә караганда, районда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары үсешен тоткарлаучы факторлар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- салым дәрәҗәсенең зур булуы;
- икътисадый тотрыксызлык;
- финанс җитмәве;
- кулланучыларның исәп-хисап ясау мөмкинлеге булмау;
- аренда түләүләренең артуы/аренда түләүләренең зур булуы;
- коммуналь хезмәтләргә тарифларның артуы;
- кредит алудагы кыенлыклар;
- партнерларның ышанычсызлыгы;
- продукция сатудагы кыенлыклар;
- квалификацияле кадрларның җитмәве;
- базарга эре көндәшлек итүчеләрнең килүе.

## 3. Кече һәм урта эшмәкәрлекне икътисадның тармакларында үстерү

Район халкының тормышын яхшыртуга юнәлдерелгән тотрыклы икътисадый үсешне тәэмин итү максатларында, эшчәнлекнең әһәмиятле төрләре ачыкланды:
- туризм инфраструктурасын үстерү;
- азык-төлек һәм эшкәртү промышленносте;
- авыл хуҗалыгы;
- социаль хезмәтләр күрсәтү тармагы.

Район территориясендә икътисадның төрле тармагына керә торган оешма һәм предприятиеләр эшчәнлек алып бара: АО «Авангард», АО «ВЗП Булгар», ООО «Болгарское ХПП», ООО «Спас коммуналь челтәрләре», АО «Капиталь төзелеш идарәсе»нең Спас филиалы, “Энергосервисның Спас район предприятиеләре» җәмгыяте, ПО «Спасский Оптторг», ООО «Спасский Торг», ООО «Икмәк музее», ООО «Зубр», ООО «ВЕРА»,ООО «СУВАР-Б»,ООО «Спасскдорстрой», ООО «Спасское районное предприятие Спасагрострой», ООО «РегионСтрой», ООО «СанТехМонтаж», ООО «Мегалитстрой», ООО «Нефтебаза».

Барысы да хезмәткәрләр саны 100гә якын булган кече предприятиеләр булып санала.

Кече һәм микропредприятиеләр структурасы анализыннан күренгәнчә, предприятиеләрнең 21 проценты сәүдә тармагында эшли, 12% - авыл хуҗалыгында һәм урман хуҗалыгында, аучылык, балыкчылык һәм балык үрчетү тармагында, 21% - төзелештә, 13% - эшкәртү тармагында, 9% йөкләр ташу һәм саклау белән шөгыльләнә, 6% күчемсез милек белән операцияләр башкара, 5% - электр энергиясе, газ, су белән тәэмин итә һәм су кертә торган предприятиеләр, көнкүреш калдыклары җыю һәм утильләштерү белән шөгыльләнүче оешмалар, 4% - кунакханә хезмәте күрсәтә торган һәм җәмәгать туклануы предприятияләре, 2% - профессиональ, фәнни һәм техник

эшчәнлек алып бару белән шөгыльләнә торган предприятиеләр, 1% - сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәт күрсәтү предприятиеләре, 6% - төрле хезмәт төрләре һәм өстәмә хезмәтләр күрсәтүче предприятиеләр.

Җитештерү тармагына караганда, товар яки продукция җитештермәү белән бәйле эшчәнлек тә күпләрнең игътибарын җәлеп итә. Бездә, мәсәлән, шәхси эшмәкәрләрнең күбесе сәүдә эше белән яратып шөгыльләнә. Районда 201 стационар сәүдә объекты бар, шуның 71е авылларда урнашкан. Шәһәрдә 139 сәүдә ноктасы, икенче төрле әйткәндә, кибетләр бар. Авылларда урнашкан кибетләрдә төрле товарларны күпләп саталар, шәһәрдә дә шулай, биредә әле тагын «Автозапчасти», «Тысяча мелочей», «Золотая жила», «Обувь», «Спорттовары», «Все для ремонта», «Подарки», «Арыш Мае», кебек махсус кибетләр, даруханәләр, «Билайн» и «Мегафон» мобиль элемтә салоннары һәм башкалар бар.

2017 елда ваклап товар сату әйләнеше 1567,9 млн. сум тәшкил итте. 2018 елда – 1585,1 млн. сум. 2019 елда ваклап товар сату әйләнеше 1630,5 млн. сумга җитәргә тиеш.

Сәүдә предприятиеләрнең сату итү мәйданы 10,1 мең.кв.м, тәшкил итә, халыкның сәүдә нокталары объектлары белән факттагы тәэминителеше 1000 кешегә күчереп исәпләгәндә 522,8 кв. метр, норматив буенча 423,5 квадрат метр булырга тиеш. Ике сәүдә комплексын төзү эшләре тәмамланып килә. 2019 елда ачылырга тиешле әлеге комплексның сәүдә мәйданы 190 кв.метр тәшкил итәчәк.

Районда җитештерү тармагының үсешенә килгәндә, аның темплары әлегә бик зур дип булмый. Дөрес, кайбер уңай үзгәрешләргә дә игътибар итми мөмкин түгел. Районда 3 шәхси эшмәкәр һәм 1 кече предприятие икмәк-булка әйберләре пешерү белән шөгыльләнә; 4 эшмәкәр иттән ярымфабрикат әзерләп сата; 9 эшмәкәр җәмәгать туклануы тармагында хезмәт күрсәтә; 2 эшмәкәр мебель, тәрәзәләр җитештерү белән шөгыльләнә; 2 эшмәкәр керамзит-бетон блоклар эшләп чыгара.

Хезмәт күрсәтү тармагында эшләүчеләр исә автомобильләргә техник хезмәт күрсәтә һәм ремонт ясый, көнкүреш техникасын ремонтлый һәм тиешле хезмәтләрнең барысын да күрсәтә, пиломатериаллар җитештерү, фотографияләр ясау, чәчтарашханә хезмәте күрсәтә. Бездә кием-салым тегү белән яратып шөгыльләнүчеләр дә юк түгел.

Моннан тыш, безнең районда төрле әйберләрне заказ буенча китереп бирү, юридик, консалтинг хезмәтләре күрсәтү, сайтлар белән эш итү өчен мөмкинлекләр җитәрлек. Эшмәкәрләр бу хакта уйлап карасыннар иде.

## 4. Кулланучылар базарын үстерү

Спас районының социаль-икътисадый үсешендә авыл хуҗалыгын үстерү, туристлар хезмәте күрсәтү, эшчәнлекнең барлык тармакларында кече

һәм урта эшмәкәрлекне үстерү төп һәм өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып тора.

Спас муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы җирләре республикадагы барлык авыл хуҗалыгы җирләренең 2,8% тәшкил итә, яки 108653 гектар, сөрү җирләренең мәйданы 93,4 мең гектар. Җирләрнең 50% тан артыгы КФХ лар өлешенә туры килә (48,0 тыс. га).

“АПКны үстерү» өстенлекле программасы эшләгән чорда районда үсеш төп өч юнәлеш буенча барды:

-терлекчелек комплексларын реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә, лизинг буенча техника, җиһаз һәм җайланмалар, нәселле терлек сатып алуга һәм башка чаралар уздыруга тотылган кредит акчасының процент өлешен субсидияләү исәбенә терлекчелек тармагын үстерү;

- шәхси ярдәмче хуҗалыкларны һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларын үстерүгә алынган кредит һәм займ ставкаларын субсидияләү исәбенә хуҗалык итүнең кече формаларын стимуллаштыру;

-авылда яшь белгечләрне (яки аларның гаиләләрен) торак төзү (сатып алу) өчен льготалы кредитлар белән тәэмин итү, торак төзү (сатып алу), башка чаралар өчен субсидияләр бирү.

Хуҗалык итүнең кече формаларына ярдәм күрсәтү программасы җитештерелгән продукция сатуны арттыруны күздә тота.

Авыл хуҗалыгын механикалаштыру зур икътисадый әһәмияткә ия, моның нәтиҗәсендә хезмәт җитештерүчәнлеге арта, продукциянең үзкыйммәте кими, билгеләнгән эшләрне тиз арада башкарып чыгу мөмкинлеге тудыра. Авыл хуҗалыгы производствосы культурасын күтәрү процессы авыл хуҗалыгын механикалаштыру – фән һәм техниканың яңа казанышларын куллану, прогрессив технологияләрне үзләштерү, авыл хуҗалыгын алга таба интенсивлаштыру кебек процесслар еблән аерылгысыз бәйле.

Районның азык-төлек базасын торгызу һәм үстерүдә төп факторларның берсе булып авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрне тиешле техника белән тәэмин итү, авыл хуҗалыгы производствосының материаль-техник базасын үстерү һәм сервис хезмәте күрсәтү санала.

Республикада техника белән тәэмин итүгә зур игътибар бирелә. Районда соңгы 5 ел эчендә 27 берәмлек трактор, 13 берәмлек ашлык уру комбайны, 147 берәмлек тагылма техника сатып алынды.

2017 елда крестьян (фермер) хуҗалыклары материаль-техник базаны ныгыту максатында үз средстволары исәбенә 49,2 миллион сумга төрле җиһаз һәм җайланмалар сатып алдылар. 2018 елда алынган шундый техника бәясе 35,2 миллион сум тәшкил итте. 2019 елда хуҗалыкларда 30 миллион сумга төрле маркадагы авыл хуҗалыгы техникасы һәм башка кирәк-яракларны сатып алырга җыеналар.

Район территориясендә 70 фермер хуҗалыгы бар, аларда үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясе җитештерәләр, бездә тагын 22 гаилә фермасы

уңышлы эшләп килә. Шуларның 9ы –югары технологияле. 2019 елда 24 баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән ике кечкенә гаилә фермасы төзү планлаштырыла. Моның өчен район бюджетыннан 400әр мең субсидия биреләчәк.

2018 елның 1 ноябренә хуҗалыклардагы, эре һәм уртача фермер хуҗалыкларындагы мөгезле эре терлекләрнең баш саны 8017не тәшкил итте. Бездә барлыгы 3572 баш савым сыер бар

2019 елда Өчкүл авылында сугым цехы (куәте – сменага 10 баш мөгезле эре терлек яки 20 баш сарык) һәм Болгарда ит эшкәртү цехы (куәте – тәүлегенә 4 тонна ит) төзелеп бетәргә тиеш.

Болгар шәһәрендә атна саен ярминкәләр уздырыла. Биредә Спас районы эшмәкәрләре һәм читтән килгән сәүдәгәрләр көндәлек товарлар, авыл хуҗалыгы продукциясен саталар. Ярминкәләрдә шулай ук шәхси хуҗалыкларда җитештерелгән бик күп продукцияне тәкъдим итәләр. Кече һәм урта бизнес субъектлары Болгарда гына түгел, республикабыз башкаласы Казанда уздырыла торган зур ярминкәләрдә дә теләп катнашалар. Саннарга килгәндә, әйтик бары тик ярминкәләрдә катнашып кына да хуҗалыклар 16,0 миллион сумлык товар саткан. 2019 елда да район хуҗалыклары һәм предприятиеләр ярминкләрдә актив катнашырга җыена.

Спас муниципаль районының республикадагы иң бай тарихи һәм табигый потенциалга ия булуын да әйтергә кирәк. Биредә төп мәдәни-тарихи мирасыбыз һәйкәле – борынгы Болгар шәһәре урнашкан. Моннан күп гасырлар элек биредә Идел буе Болгарстаны башкаласы гөрләп чәчәк аткан, монда тормыш кайнап торган.

Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгын үстерү буенча зур эшләр башкарылды. “Мәдәни мирас –Зөя утрау-шәһәрчеге һәм Борынгы Болгарны 201 –2013 елларга комплекслы үстерү программасы” нигезендә 922 елда болгар бабаларыбызның ирекле рәвештә ислам динен кабул итү хөрмәтенә Истәлек билгесе, “Ак мәчет” комплексы, казан татарларының һәм болгарларның тормыш-көнкүрешен чагылдыру өчен бөтен игенчелек эше циклын күрсәтеп бирү өчен Икмәк музее –интерактив музей, «Лекарь йорты», музейно-туристический комплекс «Һөнәрчеләр остаханәсе» музей-туристлар комплексы, памятник архитектуры «Хан сарае» архитектура һәйкәле, елга вокзалы функциясен үтәүче Болгар цивилизациясе музее, Халыкара археологик тикшеренүләр үзәге төзелде. Болгардагы тарих-архитектура музей-тыюлыгы дөньядагы урта гасырлар тарихын чагылдырган иң уникаль һәйкәлләрнең берсе, дияргә була. XIII-XIV гасырларның тарихы турында сөйли торган мондый һәйкәлләр башка беркайда да юк. 2014 елда Болгардгы тарих-архитектура комплексы ЮНЕСКОның Бөтендөнья мәдәни мирас исемлегенә 1002нче объект буларак кабул ителде.

2017 елда Спас муниципаль районына 540,9 мең турист килде. Соңгы елларда туристлар тагын да күбрәк килә башлады.

(мең кеше.)

| 2010 ел | 2012 ел | 2014 ел | 2016 ел | 2017 ел |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 51,7 | 134,0 | 285,3 | 472,0 | 540,9 |

2019 елда 700 мең кеше килер дип көтелә.

Табигать ландшафтының уникальлеге, Болгарның Кама белән Идел елгасы кушылган өлешендә урнашуы рекреация хезмәте күрсәтү һәм туризмны үстерү өчен әйбәт мөмкинлекләр тудыра.

Район буенча яңа туристик маршрутлар оештыру, авыл туризмын, ял көне турын үстерү, гөмбә һәм җиләк җыю өчен бездә шартлар җитәрлек. Балык тоту һәм аучылык туризмы өчен табигатьнең гүзәл почмаклары бик күп, бу исә күп кешене кызыксындыра. Авыл җирлекләре башлыклары әлеге мәсьәлә буенча тиешле эш алып бара.

Бездә страуслар фермасы әйбәт кенә эшли, киләчәктә инфраструктураны үстерү буенча да планнар билгеләнгән.

Дөяләр фермасының эше игътибарга лаек, дөя йоныннан эшләнгән әйберләр, сөт сату эше җайга салына. 2019 елда да Дөяләр фермасы территориясен зурайту буенча эшләр дәвам итәчәк. 2018 елда җир участогы бүлеп бирелде, территорияне төзекләндерү эшләре алып барылды.

40тан артык эшмәкәр тыюлык һәм Икмәк музее территориясендә урнашкан стационар булмаган сәүдә объектларында сувенир продукциясе җитештерү һәм сату белән шөгыльләнә, шуларның 8е үз эшчәнлекләрен 2018 елда башлап җибәрделәр. Райондагы эшмәкәрләрнең берсе 2018 елда велосипед һәм самокатларны прокатка биреп тору хезмәте күрсәтә башлады, шулай ук атта һәм көймәдә йөрүләрне оештырып җибәрде. 2019 елда кунакханә комплексы территориясендә сувенир продукциясе сату белән шөгыльләнә торган тагын берничә сәүдә ноктасы ачу планлаштырыла.

13 җәмәгать туклануы ноктасы әйбәт кенә эшли, алар берьюлы 1400 кешегә хезмәт күрсәтә ала. 2019 елда йөк автомобильләренә хезмәт күрсәтү буенча автосервис ачылырга тиеш. Анда кафе һәм кунакханә дә булачак. Болар барысы да автомобиль йөртүчеләргә уңайлы һәм җайлы булсын өчен эшләнә.

Борынгы Болгар шәһәренә килә торган туристлар санын арттыру максатында челтәрле кунакханә төзү кирәклеге турындагы мәсьәлә алга килеп басты. Спас районы җитәкчелеге кунакханә комплексын урнаштыру өчен Приволжск поселогында 25 гектар җир участогы бүлеп бирде.

2018 елның көзендә АО «ОЛ СИЗОНС ОТЕЛЬ МЕНЕДЖМЕНТ» 5 йолдызлы кунакханә комплексы "КОЛ ГАЛИ РЕЗОРТ И СПА" эшли башлады. Бу күпүзәкле комплекс гаилә белән, аерымлап һәм туристларга ял итү өчен яраклаштырылган. Комплексның Ак пулат рәвешендә төзелүе турында да әйтергә кирәк. Мунча комплексы традицион борынгы Болгар мунчасын һәм заманча йөзү бассейнын, spa-салон и фитобарны үз эченә алган. Кунакханә территориясендә төрле җиләк-җимеш бирә торган зур бакчалар барлыкка киләчәк, шулай ук туйлар һәм башка җәмәгать чаралары уздыру өчен мәйданчыклар, ачык һавада кинотеатр һәм амфитеатр булдыру күздә тотыла. Шулай ук су коену һәм пляж волейболы өчен пляж зонасы, су

спорты белән шөгыльләнү өчен мөмкинлекләр булдырылачак, көймә һәм катерлар кую урыны төзеләчәк. Кунакханәгә килүчеләргә 140 автомобильне кую өчен җир асты паркингы төзү каралган. Комплекс инфраструктурасына 300 кешегә исәпләнгән комфортабельле кунакханә номеры, конференц-заллар, ресторан керә. Кунакханә комплексы территориясендә шактый зур прогулка зонасы, велосипедта йөрү юллары, ачык балалар мәйданчыгы, теннис кортлары, мини-футбол һәм баскетбол, мини-гольф спорт мәйданчыклары, ачык бассейн төзелергә тиеш.

Идел елгасына дүрт – биш палубалы теплоходлар керә алсын өчен фарватерны тирәнәйтү эшләре башкарылды. 2018 году 118 теплоход белән 14408 турист килде. 2019 елда 125 теплоход һәм 250 метеор керү өчен 130 туроператор белән экскурсия хезмәте күрсәтүгә контракт төзелде.

Борынгы Болгар территориясендә инде 20 елдан артык Идел буе боларларының рәсми рәвештә Ислам динен кабул итү хөрмәтенә ел саен традицион “Изге Болгар җыены” уздырыла. Җыенга Россиянең бик күп төбәкләреннән милләттәшләребез килә. 2018 елда мондый чараларда 36 мең кеше катнашты.

2014 елдан башлап ел саен “Бөек Болгар” урта гасырлар сугышы фестивале уздырыла. 2017 елда фестиваль халыкара статус алды. 2018 елда уздырылган фестивальдә генә дә Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгында 40 мең тамашачы катнашты. 2019 елда да мондый чара уздыру планлаштырыла. Әлбәттә инде, быел да фестивальне карарга килоүчеләр күп булыр, дип өметләнәсе килә.

Туристлар һәм шәһәргә килә торган туристлар өчен Ржавец поселогы территориясендә “Казаклар Усадьбасы” ял базасы төзелде. Биредә балык тоту, ауга чыгу, авыл туризмы өчен бөтен мзмкинлекләр һәм шартлар тудырылган. Ял базасы берничә көнгә 140 кешегә хезмәт күрсәтә ала.

Базар икътисадына күчү белән кулланучылар кооперациясенең эше сүрелеп калмады. Ул әле дә булса халыкны, беренче чиратта авыл кешеләрен, кирәкле товарлар белән тәэмин итү буенча үзенең төп бурычын үтәүне уңышлы дәвам итә.

«Спасский  Оптторг» кулланучылар җәмгыяте һәм ООО «Спасский Торг» район территориясендәге 33 сәүдә ноктасында, шул исәптән авыл җирендәге 25 кибеттә һәм шәһәрдәге 5 кибеттә ваклап сату белән шөгыльләнә.

Лизинг буенча алган 2 автолавка белән район үзәгеннән еракта урнашкан кечкенә авылларга чыгалар һәм кирәкле тварлар саталар, алар шулай ук халыктан алынган заказларны да бик теләп үтиләр. Шулай ук Казан шәһәрендә уздырыла торган ярминкәләрдә дә актив катнашалар.

2017 елдан башлап  ПО «Спасский Оптторг» берләшмәсенә район үзәгеннән 11 километрдан арырак булган кечкенә авылларга барып, халыкка тормыш-көнкүрештә кулланыла торган әһәмиятле товарларны саткан өчен кулланучылар кооперациясе тоткан чыгымнарның бер өлешен кире кайтарып

бирә башладылар. 2018 елда 300 мең сум күләмендә субсидия алынды, 2017 елда - 342,5 мең сум.

2019-2023 елларда да район үзәгеннән читтә урнашкан кечкенә авылларга барып, халыкка көн саен кирәк булган товар сатуга зур игътибар биреләчәк.

Икътисадның барлык тармакларында да эшне тиешенчә оештыру максатында, 2019-2023 елларда очрашулар, конференцияләр, съездлар, үсеп килә торган яшь буын белән тәрбияви характердагы төрле чаралар оештыру күздә тотыла.

2019 елда юлларда сервис хезмәте күрсәтү объектлары (Бураково, Никольск авыллары), шәхси ярдәмче хуҗалыкларда җитештерелгән продукцияне сату буенча сәүдә нокталары (.Ярдам поселогы, Никольск авылы) ачылырга тиеш.

2020 елда Ржавец авылында балыкчылар һәм аучылар өчен туристик комплекс ачу күздә тотыла.

Кече һәм урта бизнес субъектлары алдында эшчәнлекнең барлдык төрләре буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту бурычы тора.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм йөзеннән 2019-2024 елларда проблемаларны ачыклау өчен халыктан, туристлар һәм килгән кунаклардан сораштыру үткәреләчәк.

Кече һәм урта бизнес субъектларыннан җирле бюджетка кергән налогка анализ ясаганда, уңай динамика күзәтелүен дә билгеләп үтәргә кирәк.

2таблица

| Күрсәткечләрнең исемлеге | 2015 ел (факт) | 2016 ел (факт) | 2017 ел (факт) | 2018 ел (факт) |
|---|---|---|---|---|
| Җирле бюджетка салым һәм салымныкы булмаган керемнәр – барлыгы мең сумнарда | 155 064,10 | 172 000,80 | 198 278,00 | 217422,50 |
| в том числе: | | | | |
| Кече һәм урта предприятиеләрдән (мең сумнарда) | 24 956,00 | 27 845,80 | 49 771,90 | 53627,70 |
| Физик затларның салымына керем (мең сумнарда) | 105 614,50 | 114132,30 | 124464,30 | 153053,20 |
| Узган елдагыга караганда (%) | 100,9 | 108,1 | 109,1 | 123,0 |

Әгәр 2016 елда кече һәм урта предприятиеләрдән салым һәм салымныкы булмаган түләүләр 27845,8 мең сум булса, 2017 елда бюджетка к акча 1,8 тапкырга күбрәк керде һәм 49527,3 мең сум тәшкил итте. Кече һәм урта эшмәкәрлек объектларыннан кергән салым һәм салымныкы булмаган акча район бюджетына күчерелгән салым һәм салымныкы булмаган акча күләменең 25 процентын тәшкил итте. 2018 елда кече һәм урта бизнес

объектларыннан керәчәк салым һәм салымныкы булмаган түләүләр 27 процентка җитте. 2019 елда күрсәтелгән хезмәт, яңа эш урыннары булдыру исәбенә бюджетка түләүләр 30 процентка кадәр җитәргә тиеш.

## 5. Яшьләр арасында эшмәкәрлекне үстерү

Яшьләр арасында эшмәкәрлекне үстерү программасы кысаларында, Болгардагы 2нче урта мәктәптә берничә елдан бирле мәктәп бизнес-компаниясе эшләп килә. Компания эшчәнлеген яхшырту максатында, аның җитәкчесе, технология укытучысы О.В.Выжленкова һәм аның укучылары эшмәкәрлек серләренә өйрәтә торган семинарларда, конференция, фестиваль һәм слетларда актив катнашалар. 2018 елның мартында педагог муниципаль дәрәҗәдә узган чарада талантлы балаларны табу һәм аларга ярдәм итү өчен технология дәресләрендә тиешле шартларны ничек булдыру кирәклеге турында туплаган тәҗрибәсе белән уртаклашты, шул ук 2018 елда «КомфортЭра» компаниясе мәктәп компанияләренең 16нчы слетында катнашты һәм “Республиканың иң яхшы мәктәп компаниясе” дипломына лаек булды, 2018 елның апрелендә компания вәкилләре Латвиянең Рига шәһәрендә уздырылган мәктәп компанияләренең Халыкара фестивалендә булдылар, бирелән катнашучылар Дипломы алып кайттылар. 2018 елның августында мәктәпнең “КомфорЭра” бизнес-компаниясе Татарстанның яшьләр министры Дамир Фәттахов белән очрашты, балаларны эшмәкәрлек эшенә өйрәтүне оештырганы өчен О.В.Выжленковага яшьләр эше министрлыгының Рәхмәт хаты тапшырылды. Ноябрьдә Ольга Владимировна эшмәкәрлеккә өйрәтүгә һәм “Яшьләр казанышы” программасын тормышка ашыруга булышлык иткәне өчен Европаның иң яхшы 17 мәктәбен бүләкләү тантанасында (Австриянең Вена шәһәре) катнашты һәм диплом белән Кубокка ия булды.

Мәктәп бизнес-компаниясен үстерүдә конкурсларның да роле бик зур. Балалар конкурсларда күп нәрсәләрне өйрәнәләр, яңа идеяләр белән рухланып яшиләр.

2017 елның язында мәктәпнең КомфортЭра компаниясе читтән торып уздырылган “Менеджмент риска” Бөтенроссия конкурсында катнашты һәм “Иң оригиналь видео” өчен махсус призга лаек булды.

2018 елның гыйнварында КомфортЭра “Будь предприимчив” бизнес-планнар конкурсының финалына чыкты; май аенда укучылар мәктәп компанияләренең Бөтенроссия интернет-ярминкәсендә җинделәр; июльдә п бизнес компания вәкилләре Белградның Сербия шәһәрендә уздырылган мәктәп компанияләренең Халыкара Ярышларында катнаштылар; ноябрьдә, «Школьные компании.Успешный старт» республика мәктәп компанияләре республика семинарында катнашып җиңүче Дипломы алдылар. 2019 елда да мәктәп-бизнес компаниясенең планнары зур, ул төрле конкурс, ярминкә, ярыш һәм семинарларда катнашырга җыена.

Район территориясендә «Спас тармак технологияләре техникумы» эшли, биредә түбәндәге белгечлекләр буенча белем бирәләр:
- автомобиль транспортына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау;
- җәмәгать туклануы предприятиесе технологиясе;
- кунакханә сервисы;
- экономика һәм бухгалтерлык учеты;
- автомеханик;
- механик-җыю эшләре слесаре ;
- повар.

«Спас тармак технологияләре техникумында» яшьләрне эшмәкәрлеккә җәлеп итү өчен төрле чаралар уздырыла, шул исәптән дәресләр, конкурслар һәм ярышлар, конференцияләр еш уздырыла.

ГБОУ СТОТ укытучысы Ю.А.Маркарян “Кече эшмәкәрлекне оештыру” программасы буенча зур эш алып бара, аның студентлары, мәсәлән, республика күләмендә уздырыла торган чараларда катнашып әйбәт нәтиҗәләргә ирештеләр:

1. Казандагы икътисад, идарә һәм хокук институтында һөнәри осталык конкурсында 1 дәрәҗәле диплом алдылар.
2. “ТИСБИ” идарә институты уздыра торган ТР яшь эшмәкәрләр форумында актив катнашып, бизнес проектлары буенча республика конкурсында лауреат дипломы алдылар.
3. Чистайдагы күп профильле көллияттә “Һөнәри осталык формуласы” республика студентларының тикшеренү эшләре һәм проектлары конкурсында үзләрен яхшы яктан күрсәттеләр.

Яшьләрне кече бизнеска тагын да күбрәк җәлеп итү максатында шулай ук 2019 елда да квартал саен гомуми белем бирү мәктәпләре, Спас тармак технллогияләре техникумы, Балалар иҗат йорты базасында кече бизнесны популярлаштыру һәм үстерү, эшмәкәрлеккә ярдәм итү өчен очрашулар, тәҗрибәле эшмәкәрләр белән мастер-класслар уздырылачак.

## 6. Промышленность мәйданчыкларын үстерү һәм резидентларны җәлеп итү

Спас муниципаль район территориясендә аккредитацияләнгән шәхси промышленность мәйданчыгы бар. Хәзерге вакытта 7 резидент эшчәнлек алып бара, алар елга һәм диңгез балыгы эшкәртү, ЖБИ, тимердән төрле әйберләр җитештерү, көнкүреш калдыклары җыю, чыгару һәм утильләштерү, агач материаллары әзерләү һәм эшкәртү, тимер җыю һәм аны урнаштыру белән шөгыльләнә.

Эш урыннары саны - 29. 2018 елның 9 аенда резидентларның акча әйләнеше 8,7 млн. сум (2016 елда – 3,3 млн. сум, 2017 елда – 5,1 млн. сум) тәшкил итте.

2019 елда резидентларның акча әйләнеше 12,0 млн. сумга җитәр дип планлаштырыла.

ООО «Болгаррыбпродукт» 2018 елда елга һәм диңгез балыгы эшкәртү буенча мини завод эшләтә башлады, 7 эш урыны булдырылды. Инвестицияләр күләме 7 млн. сумга җитте.

Промышленность мәйданчыгы территориясендә яңа производство булдыру мөмкинлеге бар, моның өчен урын да бар. Әйтик, күчемсез милек мәйданнары гына да 600 кв.метр тәшкил итә.

ООО «Регионстрой» идарәче компания промышленность мәйданчыгы территориясенә яңа резидентлар җәлеп итү буенча эшли. 2019 елда промышленность мәйданчыгына тагын бер резидент керергә тиеш.

## 7. Халыкның үзмәшгульлеге

«Үзмәшгульлекне үстерү» программасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметү буенча әһәмиятле программа булып санала. Әлеге программа кысаларында, эшсез калган кеше үз бизнесын башлап җибәрә – үзен һәм башкаларны эш белән тәэмин итә ала. Бу аеруча авыл җирендә яшәүчеләр өчен мөһим, чөнки биредә эшкә урнашу мөмкинлеге юк. Бу программа авыл кешеләре арасында бик популяр. Шунысын әйтергә кирәк, әлеге программа буенча Спас районында 2015-2018 елларда 17 кеше үз бизнесын башлап җибәрде.

Шул исәптән 2015 елда эшсез калган 6 кеше яңадан үз эшләрен башлап җибәрделәр. Алар, мәсәлән, корпуслы мебель ясау, йөкләр ташу буенча автотранспорт хезмәте күрсәтү, пилорам, эретеп ябыштыру хезмәте күрсәтү, күпьеллык үлән орлыгы үстерү, халык сәнгате продукциясе җитештерү белән шөгыльләнә. 2016 елда 4 эшсез кеше эшчәнлекнең түбәндәге төрләре: маникюр хезмәте күрсәтү, авыл җирендә сәүдә хезмәте күрсәтү, парикмахер хезмәте һәм башка хезмәтләр күрсәтү белән шөгыльләнә башлады. 2017 елда эшсез калган 3 кеше бер кыенлыкларсыз шиномонтаж, сувенир хезмәте күрсәтү, матурлык өлкәсендә хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнә башлады. 2018 елда 5 кеше йөкләр ташу буенча автотранспорт хезмәте, суши һәм роллар әзерләү һәм сату, сувенир прәннекләре әзерләү, оптика һәм күзлек ясау, матурлык хезмәте күрсәтү эшенә кереште.

2019 елда «Үзмәшгульлеккә ярдәм итү» программасы кысаларында үз бизнесын булдырырга җыенган 3 эшсез кешегә Татарстан Республикасы бюджетыннан ярдәм күрсәтеләчәк. Моның өчен без булдыклы, үз эшен башлап җибәрү белән чын-чынлап кызыксынган кешеләрне эзлибез, аларга хокукый, салым мәсьәләләре һәм башка мәсьәләләр буенча тиешле киңәш-тәкъдимнәрнең барысы да биреләчәк.

2019 елдан башлап илнең дүрт төбәгендә яңа махсус салым режимы – «Налог на профессиональный доход», кертеләчәк. Ул 2018 елның 27 ноябрендә кабул ителгән 422 нче «О проведении эксперимента по установле-

нию специального налогового режима «Налог на профессиональный доход», федераль әһәмияткә ия булган Мәскәү, в Мәскәү һәм Калуга өлкәләрендә, шулай ук Татарстан Республикасында (Татарстанда) сынап каралачак.

Яңа махсус салым режимын кешеләрне ялламыйча гына хезмәт күрсәтә яки товар җитештерү торган физик затлар, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр кулланырга мөмкин.

Әлеге махсус режимны куллануга үшмәшгульләр өчен билгеләнгән таләпләрне үтәгән очракта шәхси эшмәкәрләр дә күчә ала.

## IV. ТЕРРИТОРИЯЛӘРНЕҢ ИНВЕСТИЦИЯЛӘРНЕ НИЧЕК ҖӘЛЕП ИТҮЕНӘ БӘЯ, ЭШМӘКӘРЛЕКНЕ ҮСТЕРҮ ЮНӘЛЕШЛӘРЕ ҺӘМ КОНКРЕТ ЧАРАЛАР ИСЕМЛЕГЕ

Тарихи күзлектән чыгып караганда, Спас муниципаль район урнашкан территория элек-электән сәүдәгәрләрне, һөнәрчеләр һәм кул эше осталарын үзенә магнит кебек тартып торган. Моңа гаҗәпләнәсе дә юк, ни өчен дигәндә, бу төбәкнең география шартлары, башкала статусы, бай һәм юмарт табигать, шулай ук Болгарның Идел белән Кама елгасы кушылган урында урнашуы һәр яктан караганда да отышлы булган.

Районның туристик потенциалына анализ һәм ясалган бәядән күренгәнчә, Болгарда килгән туристларга һәм күп сандагы кунакларга тиешле югарылыкта хезмәт күрсәтү, аларның изге җирләр белән кызыксындыра алу өчен шартлар җитәрлек. Чыннан да, Болгардагы тарихи-мәдәни кыйммәткә ия булган һәйкәлләр, искиткеч гүзәл табигать, географик яктан җайлы урынга урнашкан булуы ( Идел елгасындагы туристик транзит үзәк), Казанга һәм башка өлкә үзәкләренә якында гына булуы, эре һәм танылган музей-тыюлык күпләрдә зур кызыксыну уята.

Инвестиция эшчәнлеген яңа производстволар булдырып яки тулысынча эшләтелми торган производство мәйданчыкларында гына яхшыртырга мөмкин.

Спас муниципаль районында халыкның уртача кереме республикадагы уртача күрсәткечтән ике тапкырга диярлек ким. Кулланучылар ихтыяҗын арттыру өчен керем югары булырга тиеш. Кулланучының тәкъдимен арттыру турында да уйланырга кирәк.

“Спас муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Татарстан Республикасының Спас муниципаль районында инвестиция климатын яхшырту өчен кулланылмый торган авыл хуҗалыгы җирләрен ачыклау буенча эш алып бара, мондый җирләр табылган очракта, алар реестрга кертелә. Аннары инде әлеге җир участоклары хуҗалары белән бу җирләрдән файдалану буенча сөйләшүләр алып барыла.В дальнейшем проводится работа с правообладателями данных участков по использованию. Инвентарьлаштыру нәтиҗәләре буенча 2017 елда 3757 гектардагы авыл хуҗалыгы җирләре өстәмә рәвештә әйләнешкә кертелде.

Файдаланылмый торган җир участокларын арендалауга төзелгән килешүләр суд нигезендә гамәлдән чыгарыла, соңыннан бу җирләрне әйләнешкә кертү буенча эш алып барыла.

Спас муниципаль районында крестьян (фермер) хуҗалыкларына авыл хуҗалыгы продукциясе үстерү өчен кирәк булган җирләрне бирүдә бер каршылыклар да юк.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының 2016 елның 10 октяәбрендәге 11-5 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасының Спас муниципаль районы милкендә булган милек исемлеге булдырылды. Бу җирләргә өченче кешенең хокукы юк, алардан кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары иркенләп файдалана ала. Моның өчен тиешле документларның барысын да рәсмиләштерергә генә кирәк.

Спас муниципаль районындагы бизнес вәкилләренең һәм шулай ук халыкның эшлекле активлыгы түбән булуы турында да әйтми мөмкин түгел. Моны әлеге субъектлардагы мәгълүмат дәрәҗәсенең җитешеп бетмәве, финанс грамотасы дәрәҗәсенең түбән, инвестиция проектларына тәкъдимнәрнең аз дәрәҗәдә булуы белән аңлатырга мөмкин. Эшлекле активлыкны күтәрүгә райондагы, республиканың башка муниципаль бермәлекләрендәге һәм аннан читтәге товар җитештерүчеләрнең мөмкинлеге һәм ихтыяҗы турында мәгълүмат та беркадәр ярдәм күрсәтә алыр иде.

“Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя утрау-шәһәрчеге” проектын тормышка ашыру барышында туризмга аерым игътибар бирелә.

Бүгенге көндә түбәндәге түбәндәге инвестиция бушлыгын тулыландырасы бар: Болгарга бара торган юлда сервис хезмәте күрсәтүне җайга салу, ял итү, күңел ачуның төрле формаларын оештыру, сувенир продукциясе җитештерү, район эчендә экскурсияләр алып бару, район авыллары арасында автобуслар йөрүне җайга салу, социаль эшмәкәрлекне үстерү.

Түгәрәкләп әйткәндә, бүген борчый торган проблемалар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- туристлар өчен инфраструктура тиешле дәрәҗәдә түгел;
- файдаланылмый торган авыл хуҗалыгы җирләре;
- халыкның кереме аз булуы;
- авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренең эшчәнлекнең төп юнәлешләре: авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү, аны эшкәртү һәм сату буенча кооперация системасының булмавы.

3нче таблицада проблемаларны хәл итү буенча проект һәм чаралар планы исемлеге китерелгән.

3нче таблица

Кече һәм урта эшмәкәрлекнең инвестицион җәлеп итүен һәм эшлекле активлыгын яхшырту буенча чаралар

| № п/п | Чаралар | Үтәү вакыты | Үтәү өчен җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Районга инвестицияләр (инвесторлар) җәлеп итү буенча эш төркеме төзү | 2018 | Башкарма комитет |
| 2. | Буш торган производство мәйданчыкларын, шул исәптән җир участокларын инвентарьлаштыру һәм реестр булдыру | 2019-2023 | Башкарма комитет |
| 3. | Туризм тармагын үстерү:Развитие туристской сферы:<br>- мәдәни-танып-белү туризмы, Болгарның тарихи-мәдәни ресурслары һәм истәлекле урыннары нигезендә | 2019-2023 | ТР Мәдәният министрлыгы БГИАМЗ, Туризм буенча ТР Дәүләт комитеты-Госкомитет РТ по туризму, Башкарма комитет |
| | - вакыйгалар туризмы,<br>Берничә вакыйга белән бәйле – болгарларның 922 елда Ислам динен кабул итүе | 2019-2023 | ТР Мәдәният министрлыгы БГИАМЗ, Туризм буенча ТР Дәүләт комитеты,районБашкарма комитеты |
| 4. | Ел саен уздырыла торган “Бөек Болгар” тарихи реконструкция фестивале | 2019-2023 | ТР Туризм буенча дәүләт комитеты |
| 5. | Туристик инфраструктура булдыру:<br>- кунакханәләр кемпенглар, кунакханә йортлары | 2019-2023 | ТР Мәдәният министрлыгы, Туризм буенча ТР Дәүләт комитеты Республиканың “Яңарыш” Фонды « Шәхси инвестор |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - җәмәгать туклануы предприятиеләре<br><br>- сувенир продукциясе җитештерү һәм сату предприятиесе<br><br>-туристларга транспорт хезмәте күрсәтү, шул исәптән судноларкомпаниясен җәлеп итү | 2019-2023<br><br>2019-2023<br><br>2019-2023 | Шәхси инвесторлар Спас районы Башкарма комитеты<br><br>БГИАМЗ Шәхси инвесторлар<br><br>ТР Мәдәният министрлыгы, Туризм буенча ТР Дәүләт комитеты БГИАМЗ, Шәхси инвесторлар |
| 6. | Музей-тыюлык структурасын һәм материаль-техник базасын үстерү | 2019-2023 | ТР Мәдәният министрлыгы, БГИАМЗ |
| 7. | Музей-тыюлыкны фәнни-белем бирү эшчәнлеген үстерү | 2019-2023 | Тр Мәдәният министрлыгы, БГИАМЗ |
| 8. | Терлекчелек фермалары төзү (реконструкцияләү) һәм сыерлар сатып алу | 2019-2023 | Спас районы Башкарма комитеты, ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы |
| 9. | Чәчү комплекслары сатып алу | 2019-2023 | Район Башкарма комитеты, Авыл хуҗалыгы министрлыгы |
| 10. | 24 баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән ферма төзү, шул исәптән 12 башка исәпләнгән ферма төзү | 2019-2023 | Район башкарма комитеты Авыл хуҗалыгы министрлыгы |
| | Нәселле терлекләр сатып алу | 2019-2023 | Район Башкарма комитеты, Авыл хуҗалыгы министрлыгы |
| 12. | Энергияне саклый торган техника сатып алу | 2019-2023 | Район Башкарма комитеты, Авыл хуҗалыгы министрлыгы |
| 13. | Сөт фермасына җиһазлар сатып | 2019-2023 | Район башкарма |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | алу | | комитеты, Авыл хуҗалыгы министрлыгы |
| 14. | Сугым цехы төзү | 2017-2019 | Шәхси инвестор |
| 15. | Ит эшкәртү цехы төзү | 2015-2019 | Шәхси инвестор |
| 16. | Көнбагыш мае җитештерү цехы төзү | 2018-2019 | Шәхси инвестор |
| 17. | Авыл хуҗалыгы продукциясе сатып алу өчен кооператив төзү | 2019 | Эшмәкәр Мөхәммәтов Р.В. |
| 18. | Йөк автомобильләренә техникхезмәт күрсәтү станциясе төзү | 2019 | Шәхси инвестор |
| 19. | Эш эшкәртү цехының фирмалы кибетен төзү | 2019 | Шәхси инвестор |
| 20. | Сәүдә комплексы төзү | 2019 | Шәхси инвестор |
| 21. | Ржавецта балыкчылык һәм аучылык өчен туристлар комплексын төзү | 2020 | Шәхси инвестор |
| 22. | Кафеда сыр җитештерүне җайга салу | 2019 | Шәхси инвестор |

## V. ПРОГРАММАНЫҢ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТЕЛЕШЕ

Ресурсларның төп төрләре булып тора: матди ресурслар, интеллектуаль ресурслар, персонал, финанслар.

Материаль ресурслар: бу категориягә җитештерү куәте, биналар, җиһазлар, транспорт чаралары, сәүдә нокталары һәм дистрибуция челтәрләре кебек физик объектлар керә.

Интеллектуаль ресурсларга интеллектуаль милек, мәсәлән, сәүдә маркалары, милек хокуклары белән якланган ябык мәгълүматлар, патентлар һәм автор хокуклары, партнер һәм клиент мәгълүмат базалары керә. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бу юнәлештә булган буш урынны капларга кирәк.

Персонал: персонал сайлау – теләсә кайсы бизнес өчен бик мөһим бурыч. Район территориясендә “Спас тармак технологияләре техникум” Дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе эшләп килүенә карамастан, Спас муниципаль районы территориясендә икътисадның кайбер тармакларында квалификацияле кадрлар җитеп бетми.

Финанслар: теләсә нинди бизнесны алып бару өчен финанс мөмкинлекләре булуы зарур. Республика территориясендә финанс ярдәмен “Татарстан Республикасы эшмәкәрлеккә ярдәм итү фонды” коммерцияле

булмаган оешма, “Татарстан Республикасы гарантия фонды” коммерцияле булмаган оешма, бизнес-инкубаторлар күрсәтә.

Район территориясендә 2 банк: «Ак Барс» гаммәви акционерлык җәмгыяте һәм «Россия Саклык банкы» гаммәви акционерлык җәмгыяте филиаллары эшли.

Заемнарны күбесенчә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр язгы чәчү һәм урып-җыю кампаниясе чорында ала.

Башка эшчәнлек тармакларында мәшгуль булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары үз акчаларыннан файдалана.

Программаны 2019-2023 елларда тормышка ашыру өчен, 12440,0 мең сум акча кирәк булачак, аларның:

- Татарстан Республикасы бюджеты хисабына – 4440,0 мең сум (халык үз-үзен эш белән тәэмин итү программасы, кулланучылар кооперациясе оешмаларына район үзәгеннән 11 километрдан ераграк урнашкан торак пунктларга беренче ихтыяҗ товарларын китерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау);

- Спас муниципаль районы бюджеты хисабына – 8000,0 мең сум (гаилә фермаларын төзү һәм реконструкция ясауга).

Программаны тормышка ашыруга юнәлдерелгән акчаларның гомуми күләменнән:

Таблица 4

| **№** | **Чыгым чыганаклары һәм юнәлешләре** | **Финанс чыгымнары ( мең сум)** | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **барлыгы** | **шул исәптән еллар буенча** | | | | |
| | | | **2019** | **2020** | **2021** | **2022** | **2023** |
| 1. | Барлыгы финанс чыгымнары | 12440,0 | 2488,0 | 2488,0 | 2488,0 | 2488,0 | 2488,0 |
| | Шул исәптән: | | | | | | |
| 2. | Татарстан Республикасы бюджеты | 4440,0 | 888,0 | 888,0 | 888,0 | 888,0 | 888,0 |
| | Эшмәкәрлек эшчәнлеге рәвешендә халыкның үз-үзен эш белән тәэмин итүен оештыру | 2940,0 | 588,0 | 588,0 | 588,0 | 588,0 | 588,0 |
| | Кулланучылар кооперациясе оешмаларына район үзәгеннән 11 километрдан ераграк урнашкан торак пунктларга беренче ихтыяҗ товарларын китерүгә бәйле чыгымнарның бер | 1500,0 | 300,0 | 300,0 | 300,0 | 300,0 | 300,0 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | өлешен каплауга субсидияләр бирү | | | | | | |
| 3. | Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы бюджеты | 8000,0 | 1600,0 | 1600,0 | 1600,0 | 1600,0 | 1600,0 |
| | Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товар, хезмәтләр, эшләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү | 8000,0 | 1600,0 | 1600,0 | 1600,0 | 1600,0 | 1600,0 |

Татарстан Республикасы Спас мунииипаль районында 2019-2023 елларда кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү программасы фаразлау рәвешендә эшләнгән һәм тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## VI. КУРКЫНЫЧ КИТЕРЕП ЧЫГАРА ТОРГАН ОЧРАКЛАРГА БӘЯ БИРҮ, АЛАРНЫ КИМЕТҮ ЧАРАЛАРЫ

Куркыныч китереп чыгара торган очраклар (алга таба – очраклар) – кече һәм урта эшмәкәрлек объектлары эшчәнлегенә тискәре йогынты ясап, чыгымнарга китерә яки керемне мөмкин булганнан азрак күләмдә алу шартларының килеп чыгу мөмкинлеге.

Кече һәм урта эшмәкәрлеккә өчен табигый-климатик, производство, сәүдә, финас һәм инвестиция очраклары куркыныч тудырырга мөмкин.

**Табигый-климатик очраклар** гадәттә авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә начар һава шартлары аркасында уңышның һәм авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүнең күләме кимүе аркасында яный.

Һава шартларының начар булуы шулай ук туристлар агымының кимүенә дә китерә.

**Производство очраклары** кечкенә һәм урта предприятиеләрнең продукция җитештерү, ресурслар белән тәэмин ителү һәм техника белән тәэмин ителүенә бәйле. Әгәр предприятие ресурслары дөрес бүленмәсә, бу предприятие эшчәнлегенә йогынты ясаячак. Шушы сәбәпләр мәҗбүри рәвештә җитештерү күләменең, продукция бәясенең, сату күләменең кимүенә, дөрес кулланмау аркасында сарыф ителгән материалларга чыгымнарның артуына китерә. Бу очракларның йогынтысы эшчәнлеккә, эшмәкәрнең белемнәренә һәм тәҗрибәсенә бәйле.

**Сәүдә очраклары** продукцияне сату вакытында югалтулар килеп чыгу ихтималы белән бәйле. Сәүдә куркынычларының төп сәбәпләре: конкурен көрәше көчәю; ихтыяҗ һәм тәкъдимнәр нисбәте үзгәрү; тәэмин итү һәм сату шартлары үзгәрү; килешү йөкләмәләрен бозу; сату каналларын югалту һ. б.

Базарларга керү кече һәм урта эшкуарлык өчен җитди проблема булып тора. Кече предприятиеләр еш кына күбрәк продукция җитештерергә әзер һәм сәләтле, әмма базарларга керү мөмкинлеге булмау сәбәпле, җитештерүне киңәйтүдән баш тартырга мәҗбүр. Бу очракта базар инфраструктурасының кимчелекләре кече һәм урта эшкуарлык үсешен тоткарлаучы өстәмә фактор булып тора.

**Финанс очраклары** кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының банклар һәм башка финанс институтлары белән мөнәсәбәтләре өлкәсендә барлыкка килә. Финанс тотрыксызлыгы аркасында кечкенә һәм урта предприятиеләргә читтән финанслауны алу кыен. Хәзерге вакытта күп кенә хуҗалык итүче субъектларның кредит буенча залог булырлык милке юк. Шулай ук финанс куркынычларына эчке икътисадның тотрыксызлыгы, сәүдәгә чикләүләр кертү, таможня пошлиналарын үзгәртү һәм башка сәбәпләр керә.

**Инвестиция очраклары** инвестиция проектларын гамәлгә ашыру барышында аз табыш алу яки табышны югалту мөмкинлеген аңлата. Мәсәлән, яңа техника, җиһазлар сатып алу, производство биналары төзү һәм башкалар.

Кече һәм урта эшмәкәрлек өчен санап үтелгән куркынычларны бетерү яки киметү өчен мондый чаралар күрергә мөмкин: иминиятләштерү, кооперация һәм интеграция, мәгълүматлаштыру, кече һәм урта эшкуарлык субъектларын укыту, эшчәнлекнең барлык өлкәләрендә яңа технологияләр куллану.

Кече һәм урта бизнес субъектлары өчен булган куркынычларны киметү һәм аларны җиңү өчен Спас муниципаль районында Андриянова М. Н. рәислегендә эшкуарлыкны үстерү буенча Иҗтимагый совет эшли. Иҗтимагый совет составы 2012 елның февралендә эшкуарлар конференциясендә сайланды. Даими рәвештә Иҗтимагый совет утырышлары уздырыла, эшкуарларның актуаль һәм проблемалы мәсьәләләре тикшерелә.

Эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектлары тарафыннан карарлар кабул итүне һәм гамәлгә ашыруны таләп итә торган проблемалар:

- кече эшмәкәрлек субъектларының түбән социаль җаваплылыгы (ялланган хезмәткәрләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштермәү, хезмәткә түләү фондын киметеп күрсәтү һәм аны конвертта түләү, мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе һәм социаль иминият турындагы законнарны үтәмәү);
- кече эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлек алып бара торган икътисад тармакларының диспропорциясе (күмәртәләп һәм ваклап сату өлкәсенең шактый үсеше фонында җитештерү тармаклары җитәрлек дәрәҗәдә үсми).

Булган каршылыкларны җиңеп чыгу һәм Спас районында кече эшкуарлыкны алга таба үстерү бары тик урыннарда аның үсеше өчен уңай шартлар тудыру, мәгълүмат, белем бирү, консультация, фәнни-техник, технологик, финанс юнәлешләрендә комплекслы һәм адреслы ярдәм күрсәтү,

милек белән тәэмин итү, барлк хезмәтләрне күрсәтү, эшлекле элемтәләр һәм кооперацияне җайга салу нигезендә, шулай ук эшмәкәрләргә кирәк булган башка аспектларда ярдәм күрсәтү юлы белән генә мөмкин. Программа билгеләнгән максатларга ирешү өчен җирле хакимият органнарының, шулай ук дәүләтнеке булмаган оешмаларның көчләрен берләштерергә һәм оптимальләштерергә мөмкинлек бирәчәк.

## VII. ПРОГРАММАНЫҢ ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН ИКЪТИСАДЫЙ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕ, ПРОГРАММА БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ ҺӘМ ҮТӘЛЕШЕН КОНТРОЛЬДӘ ТОТУ

Программа Спас муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне алга таба үстерү өчен уңай шартлар тудыруга юнәлдерелгән чаралар комплексын үз эченә ала.

Программаны үтәү ярдәм итәчәк:

- районда икътисадый һәм социаль тотрыклылык элементларының берсе буларак, кече һәм урта эшмәкәрлекнең тотрыклы эшчәнлеген булдыруны стимуллаштыра торган уңай икътисадый мохит формалаштыру;
- кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү темпларын арттыру, кече предприятиеләрне икътисадый яктан ныгыту һәм эшчәнлек өлкәләрен киңәйтү;
- районның берләштерелгән бюджетының салым керемнәре гомуми суммасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан җирле бюджетка керемнәрнең артуы, халыкны эш белән тәэмин итүнең өстәмә мөмкинлекләре барлыкка килү, кече һәм урта эшмәкәрлектә мәшгуль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы дәрәҗәсен күтәрү;
- товар базарын көндәшлеккә сәләтле продукция һәм җирле производство хезмәтләре белән баету;
- кече һәм урта эшмәкәрлекнең социаль җаваплылыгын арттыру.

Программа чараларын тормышка ашыру барышын ведомствоара координацияләүне һәм контрольне Спас муниципаль районы Советы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты, Программаны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган бюджет акчаларыннан файдалануны контрольдә тотуны тапшырылган вәкаләтләр кысаларында «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасы гамәлгә ашыра.

2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү программасын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә 2023 елга түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү көтелә:

- тулаем территориаль продуктта кече һәм урта бизнесның өлешен 30% ка кадәр арттыру.

- предприятиеләр һәм оешмалар хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача санында (ике эшне башкаручы чит кешеләрдән тыш) кечкенә предприятие хезмәткәрләренең (ике эшне башкаручы чит кешеләрдән тыш) уртача исемлек санын 23% ка кадәр арттыру.

- Кече предприятиеләр хезмәткәрләренең уртача айлык хезмәт хакын 19 мең сумга кадәр арттыру.

- Җирле бюджетка кече һәм урта предприятиеләрдән салым һәм салым булмаган керемнәрне 71,9 млн. сумга кадәр арттыру.

## VIII. НӘТИҖӘЛӘР ҺӘМ КУШЫМТАЛАР

Спас муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү программасын уңышлы гамәлгә ашыру өчен түбәндәге чараларны башкарырга кирәк:

1. Хокукый базаны камилләштерү һәм кече һәм урта эшкуарлыкны нәтиҗәле үстерү өчен киртәләрне киметү.
2. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс-кредит һәм милек ярдәме күрсәтү.
3. Кече һәм урта эшкуарлыкка мәгълүмат-консультация ярдәмен күрсәтү.
4. Эшмәкәрнең уңай имиджын һәм кече һәм урта бизнес турында уңай җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру.
5. Кече һәм урта эшмәкәрлек өчен квалификацияле кадрлар әзерләү.
6. Яшьләр һәм эшсезләрнең эшмәкәрлек инициативасын хуплау һәм стимуллаштыру.
7. Товарлар һәм хезмәтләр базарында конъюнктураны билгеләү. Кече һәм урта эшмәкәрлекнең агымдагы торышын анализлау.

Таблица 5

## Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында 2019-2023 елларга кече һәм урта эшмәкәрлекнең үсеше буенча төп күрсәткечләр

| № п/п. | Күрсәткечләр | Үлчәү берәмлеге | 2019 ел | 2020 ел | 2021ел | 2022 ел | 2023 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кече һәм микропредприятиеләр саны | берәмлек | 87 | 89 | 90 | 90 | 92 |
| 2 | Кече предприятиеләрдә эшлүчеләрнең (шул исәптән микропредприятиеләрдә) уртача саны | кеше | 662 | 672 | 680 | 685 | 690 |
| 3 | Шәхси эшмәкәрләрне исәпкә алып, кече предприятиеләрдә эшләүчеләр саны (шул исәптән үз-үзләрен эш белән тәэмин итүчеләрне легальләштерү) | кеше | 1564 | 1583 | 1613 | 1664 | 1710 |
| 4 | Кече предприятиеләр әйләнеше (микропред-приятиеләрне исәпкә алып) | млн. сум | 950,0 | 960,0 | 970,0 | 980,0 | 1005,0 |
| 5 | Кече предприятие хезмәткәрләренең (микро-предприятиеләрне исәпкә алып) уртача айлык хезмәт хакы | сум | 15500 | 16000 | 16500 | 17000 | 19000 |
| 6 | Җирле бюджетка кече һәм урта эшмәкәрлектән салымнар һәм салым булмаган керемнәр | млн. сум | 56,8 | 60,0 | 63,6 | 67,5 | 71,9 |
| 7 | Тулаем территориаль продуктта кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өлеше | процент | 29,0 | 29,2 | 29,3 | 29,5 | 30,0 |
| 8 | Төзелгән контрактларның санында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары төзегән муниципаль контрактлар өлеше | процент | 50 | 51 | 52 | 52 | 55 |

# IX. ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП ЧАРАЛАРЫ

Таблица 6

| № п/п | Бурыч | Төп чаралар | Программа чараларын башкаручы | Төп чараларны башкару вакыты | Финанслау чыгынаклары |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | Спас муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекнең үсеш темпларын арттыру | Кече эшкуарлык субъектларына дәүләт ярдәмен күрсәтү кысаларында хөкүмәтнең федераль һәм республика структураларына ярдәм итү | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге, Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе | 2019-2023 еллар | Финанслаусыз |
| | Кече һәм урта эшмәкәрлекнең конкурентлыкка сәләтен һәм инвестиция кыйммәтен арттыру | Район икътисадының өстенлекле юнәлешләрен үстерү максатында кече эшмәкәрлек субъектларын районда җир участоклары, торак булмаган биналар белән тәэмин итүдә ярдәм | Спас муниципаль район Советы, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары, җир һәм милек хокуклары палатасы | 2019-2023 еллар | Финанслаусыз |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Яшьләр эшмәкәрлеген үстерүгә ярдәм күрсәтү | Инициативалы, җаваплы кешеләргә икътисадның өстенлекле тармакларны үз эшен оештырырга мөмкинлек бар икәне турында хәбәр итү максатында эшмәкәрлек субъектларының район Мәшгульлек үзәге белән хезмәттәшлеген оештыру һәм аларга җирле үзидарә органнары ягыннан ярдәм күрсәтү | ДКИ «Спас районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге » | 2019-2023 еллар | Республика бюджеты акчалары |
| | | Тәҗрибәле шәхси эшмәкәрләр белән мастер-класслар уздыру | Эшкуарлыкка ярдәм итү департаменты вәкилләре, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты | 2019-2023 еллар | Финанслаусыз |
| | | Яшьләрне эшкуарлыкка җәлеп итүче чаралар | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты Яшьләр | 2019-2023 еллар | Финанслаусыз |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | комплексы, шул исәптән өйрәтү, мәгъл.мат белән тәэмин итү, конкурслар һәм ярышлар, ярминкәләр, конференцияләр һәм башкалар уздыру | эше, спорт һәм туризм бүлеге | | |
| | | Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр – товарлар, хезмәтләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты, Финанс-бюджет пала-тасы | 2019-2023 еллар | Расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә район бюджеты |
| | | ТР Министрлар Кабинеты Карарлары, ТР Икътисад министрлыгы, ТР туризм буенча комитеты боерыклары нигезендә туризм үсеше буенча республика конкурсларында һәм программаларында катнашу | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты икътисад һәм фаразлау бүлеге, яшьләр эше, спорт һәм туризм бүлеге | 2019-2023 еллар | Финанслаусыз |
| | Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен | Законнар үзгәрүгә бәйле, кече эшмәкәрлек | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты | 2019-2023 еллар | Финанслаусыз |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | кадрлар әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификацияне күтәрү системасын үстерү | мәсьәләләре буенча практик семинарлар уздыру | икътисад һәм фаразлау бүлеге Мәшгульлек үзәге, салым хезмәте, Пенсия фонды белгечләре катнашуында | | |
| | | Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләр, хезмәтне саклау мәсьәләләре буенча эшмәкәрләргә методик һәм практик ярдәм күрсәтү | ДКИ «Спас районы халкны эш белән тәэмин итү үзәге» | 2019-2023 еллар | Финанслаусыз |
| | | Техникумда укучыларны урта һөнәри белемнең лицензия һәм аккредитация үткән һөнәрләренә өйрәтү | «Спас тармак технологияләре техникумы» | 2019-2023 еллар | Финанслаусыз |
| | Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында мәдәни-тарихи | Теплоходлар һәм метеорлар керү турында килешүләр төзү, туроператорлар | БГИАМЗ, ТР туризм буенча Дәүләт комитеты | 2019-2023 еллар | Финанслаусыз |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | мирасны саклауга һәм популярлаштыру өлкәсендә эшләүче кече эшмәкәрлек үсешенә ярдәм (сәнгать кәсепләре, шәһәр төзелеше һәм башка-лар) | белән экскурсия хезмәтенә килешүләр төзү | | | |
| | | «Изге Болгар җыены» тантанасын уздыру «Бөек Болгар» урта гасырлар сугышы халыкара фестивален уздыру | БГИАМЗ, ТР туризм буенча Дәүләт комитеты, ТР Спас муниципаль Районы башкарма комитеты | 2019-2023 еллар | Финанслаусыз |
| | Эшмәкәрлек эшчәнлеген мәгълүмат белән тәэмин итү системасын камилләштерү | Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү тармагында уздырылган чараларны яктырту | Спас муниципаль Район Советы, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты | 2019-2023 еллар | Финанслаусыз |
| | | Кече эшмәкәрлек субъектларына мәгълүмат ярдмен күрсәтү | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге | 2019-2023 еллар | Финанслаусыз |
| | | Кече эшмәкәрлек | Спас муниципаль | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | субъектлары, җирле үзидарә органнары катнашуында «түгәрәк» өстәлләр, семинарлар, конфе-ренцияләр уздыру; эшкуарлык эшчәнлеген алып бару мәсьәләләре буенча эшмәкәрләргә адреслы ярдәм күрсәтү | Район Советы, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты, Эшмәкәрлекне үстерү буенча җәмәгать советы | 2019-2023 еллар | Финанслаусыз |
| | Кече һәм урта эшмәкәрлекнең социаль җаваплылыгын һәм нәтиҗәлелеген арттыру | Кече эшмәкәрлек субъектларында уртача айлык эш хакын арттыру, Спас муниципаль районы бюджетында эшмәкәрлек субъектларыннан кергән салымнарның өлешен арттыру | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары | 2019-2023 еллар | Эшмәкәрлек субъектларының үз акчалары |
| | Үз-үзләрен эш белән тәэмин итүчеләрне үз статусын рәсмиләштерергә стимуллаштыру | Гражданнар җыеннарында халык белән һөнәри керемгә салым рәвешендә махсус салым | МРИ ФНС № 12 по РТ, Исполнительный комитет Спасского муниципального | 2019-2023 годы | Без финансирования |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | режимын куллану буенча пилот проектын тормышка ашыру турында мәгълүмат-аңлату эшен үткәрү | района РТ, авыл җирлеге башлыклары, ДКИ “Спас районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” | | |
| | | Һөнәри керемгә салым рәвешендә махсус салым режимын куллану буенча пилот проектын тормышка ашыру турында мәгълүматны Спас муниципаль районы сайтында урнаштыру, «Новая жизнь» (“Яңа тормыш”) газетасында язмалар бастыру | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты, «Новая жизнь» (“Яңа тормыш”) район газетасы редакциясе | 2019-2023 еллар | Финанслаусыз |
| | | Гражданнар салым түләмичә генә арендага бирә торган күчемсез милек объектлары базасын булдыру максатында күпфатирлы йортлар активы һәм район | Болгар шәһәр башкарма комитеты, «Шеронова 23» милекчеләр ширкате, «УК Спасского района» ҖЧҖ | 2019-2023 еллар | Финанслаусыз |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | идарәче компанияләре белән бердәм киңәшмәләр үткәрү | | | |
| | | Һөнәри керемгә салым түләмичә генә эшләр һәм хезмәтләр башкаручы затларга мониторинг ясау буенча эшне башкару | ТР буенча Федераль салым хезмәтенең №12 районара инспекциясе, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты, Болгар шәһәре башкарма комитеты, авыл җирлеге башлыклары | 2019-2023 еллар | Финанслаусыз |
| | | Ачыкланган үз-үзен эш белән тәэмин итүче гражданнар буенча мониторинг алып бару п | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты | 2019-2023 еллар | Финанслаусыз |
| | Яшьләрне һәм социаль яктан якланмаган гражданнарны эшмәкәрлек эшчәнлегенә җәлеп итү. Социаль эшмәкәрлекне үстерү һәм ярдәм итү. | Кече эшмәкәрлек субъектларына мәгълүмат ярдәмен күрсәтү | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге | 2019-2023 еллар | Финанслаусыз |
| | | Кече эшмәкәрлек субъектлары, җирле | Спас муниципаль Район Советы, | 2019-2023 | Финанслаусыз |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | үзидарә органнары катнашуында «түгәрәк» өстәлләр, семинарлар, конфе-ренцияләр уздыру; эшмәкәрләргә эшкуарлык эшчәнлеген алып бару сораулары буенча адреслы ярдәм күрсәтү | ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты, Эшмәкәрлекне үстерү буенча җәмәгать советы | еллар | |